**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ БОЛЬШЕЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

**«15» август 2022 ел** **№ 71**

Олы Җәке авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында Олы Җәке авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1.Олы Җәке авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге милкендә булган мөлкәтне аукционда сату тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 27 сентябрендәге 25 номерлы карары;
- «Олы Җәке авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»2006 елның 6 августындагы 10 номерлы карары;

2 Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Олы Яке авылы Мәктәп урамы 1 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт ( Олы Яке мәдәният йорты бинасы).

Олы Җәке Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы Ф. А. Фәйзуллина